КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 декабрь г.Казань № 1160

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2020 ел, 30 декабрь, 1239 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын раслау турында» 2020 ел, 30 декабрь, 1239 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 9 июнь, 445 нче; 2021 ел, 26 июль, 656 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазын сатып алу һәм ремонтлау буенча чаралар планын билгеләнгән тәртиптә раслау буенча;

квалификация күтәрү программалары буенча медицина хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазын сатып алу һәм ремонтлау буенча чаралар планына кертү өчен чараларны сайлап алу критерийларын раслау буенча.»;

әлеге карар белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасында:

II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кайбер онкологик авырулар белән авырганда 21 яше тулмаган пациентларга 18 яшькә кадәр башланган дәвалануны дәвам итү максаты белән беренчел махсуслаштырылган медицина-санитария ярдәме, махсуслаштырылган, шул исәптән югары технологияле, медицина ярдәме «балалар онкологиясе» юнәлеше буенча балаларга медицина ярдәме күрсәтүче медицина оешмаларында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан расланган медицина ярдәме күрсәтү тәртибендә билгеләнгән очракларда һәм шартларны үтәгәндә күрсәтелергә мөмкин.»;

VIII бүлекнең 8 пунктында:

уникенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«медицина күрсәткечләре буенча дәвалануны туктаткан, пациентны медицина оешмасының бер бүлегеннән икенчесенә күчергән, пациентка тәүлек буе эшли торган стационардан көндезге стационарга һәм көндезге стационардан тәүлек буе эшли торган стационарга медицина ярдәме күрсәтү шартлары үзгәргән, яман шеш авырулары булганда дарулар белән дәвалана торган медицина ярдәмен күрсәткән һәм дәвалану барышында пациентка медицина ярдәмен түләү өчен сайлап алынган дарулар белән дәвалану схемасы белән чагыштырганда, объектив сәбәпләр буенча тулы күләмдә күрсәтмәгән очракларда, шул исәптән симптоматик дәвалау барышында авыруны туктатып булмый торган дәвалануны дәвам итүгә зарарлы булуын күрсәтә торган абсолют билгеләр барлыкка килгәндә дәвалануны туктаткан, пациентны башка медицина оешмасына күчергән, алга таба дәваланудан язма рәвештә баш тартып, пациент медицина оешмасыннан вакытыннан алда чыккан, үлгән, пациент хастаханәгә салынган (дәвалана башлаган) көннән 3 көн (3 көнне кертеп) үткәнгә кадәр хастаханәдән чыккан очракта (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2299 номерлы карары белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына 5 кушымтада китерелгән авырулар, авыру хәлләре төркемнәре буенча медицина ярдәме күрсәткән очрактан тыш) медицина ярдәме күрсәтүнең туктатылган очрагы өчен;»;

унбишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«медицина күрсәткечләре буенча дәвалануны туктаткан, пациентны медицина оешмасының бер бүлегеннән икенчесенә күчергән, пациентка тәүлек буе эшли торган стационардан көндезге стационарга һәм көндезге стационардан тәүлек буе эшли торган стационарга медицина ярдәме күрсәтү шартлары үзгәргән, яман шеш авырулары булганда дарулар белән дәвалана торган медицина ярдәмен күрсәткән һәм дәвалану барышында пациентка медицина ярдәмен түләү өчен сайлап алынган дарулар белән дәвалану схемасы белән чагыштырганда, объектив сәбәпләр буенча тулы күләмдә күрсәтмәгән очракларда, шул исәптән симптоматик дәвалау барышында авыруны туктатып булмый торган дәвалануны дәвам итүгә зарарлы

булуын күрсәтә торган абсолют билгеләр барлыкка килгәндә дәвалануны туктаткан, пациентны башка медицина оешмасына күчергән, алга таба дәваланудан язма рәвештә баш тартып, пациент медицина оешмасыннан вакытыннан алда чыккан, үлгән, пациент хастаханәгә салынган (дәвалана башлаган) көннән 3 көн (3 көнне кертеп) үткәнгә кадәр хастаханәдән чыккан очракта (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы турында» 2020 елның 28 декабрендәге 2299 номерлы карары белән расланган 2021 елга, 2022 һәм 2023 еллар план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасына 5 кушымтада китерелгән авырулар, авыру хәлләре төркемнәре буенча медицина ярдәме күрсәткән очрактан тыш) медицина ярдәме күрсәтүнең туктатылган очрагы өчен;»;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Профилактик медицина тикшерүләренең һәм диспансеризацияләрнең финанслар белән тәэмин ителеше беркетелгән затлар өчен җан башына финанслау нормативына кертелә һәм медицина оешмасы эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен исәпкә алып («Россия Федерациясендә гражданнарның сәламәтлеген саклау нигезләре турында» 2011 елның 21 ноябрендәге 323-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан раслана торган тәртипләр нигезендә үткәрелә торган профилактик медицина тикшерүләренең һәм диспансеризацияләрнең билгеләнгән күләме күрсәткечләрен кертеп) гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин